**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422870, РТ БазарлыМатакавылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

14.12.2018 г. № 469

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ
# КАРАР

Әлки муниципаль районы башкарма комитетының 03.02.2017 ел, 32№
«Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы ихтыяҗларын тәэмин
итү өчен сатып алулар өлкәсендә муниципаль мәгълүмат системаларын
эшләү һәм алардан файдалану тәртибен раслау турында" Карарына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 30 июнендәге 768 номерлы карары нигезендә Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә муниципаль мәгълүмат системаларын эшләү һәм куллану тәртибен раслау турында " 2017 елның 3 февралендәге 32 номерлы карарына (алга таба-тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Тәртипнең 4 пунктындагы 3 пунктчасына «көчәйтелгән электрон имза» сүзләрен «контракт системасы турында Федераль закон белән каралган электрон имза " сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең территориаль үсеш буенча урынбасары Э. Г. Нуруллинга йөкләргә.

Әлки муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесе — Йосыпов И.В.